ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**18.07.2016 ел** **№ 17**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында” Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын расларга:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашлауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Васыятьләр һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр һәм зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.8. Күченеп килергә мәҗбүр булганнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

1.10. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).

2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 17 июнендәге 10 номерлы карарын 2015 елның 4 ноябрендәге 2 номерлы үзгәрешләр белән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров